РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Микулинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.Микулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «05»ноября 2025г.** **№ 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм: :

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 18 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 18 ноябрендә 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр

– Гражданнар җыенын үткәрү урыны-Дмитриевка авылы, Тургай ур., 5 й.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.:

-2025 елның 7 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Микулино авылы, Совет ур., 74 йорт, Дмитриевка авылы, Тургай ур., 5 йорт;

- Дмитриевка авылында сайлау хокукына ия кешеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Дмитриевка авылы халкына массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту ).

“КАРШЫ” “ӨЧЕН”

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//Aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Микулино авылы, Совет ур., 74 йорт, Дмитриевка авылы, Тургай ур., 5 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: И.А.Такиулин